**СОВЕТ**
**Бимского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Бима авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2022 ел Бима авылы № 29-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең гавами тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 13.08.2018 елның 40-3 номерлы Татарстан Республикасы Бима авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 255-ФЗ номерлы федераль законы нигезендә, АИС Кодекс системасына хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең гавами тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 13.08.2018 елның 40-3 номерлы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.Г. Ишпаев